**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «28» августыннан № 221

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуваш Чебоксары төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуваш Чебоксары төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксары «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесен кушу юлы белән үзгәртеп кору турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 57 - 60 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 гыйнварындагы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуваш Чебоксары төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксары «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесен кушу юлы белән үзгәртеп кору процедурасын үткәрергә.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуваш Чебоксары төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксары «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесен кушу юлы белән Чуаш Чабаксары авылы, Пролетар урамы, 23 нче йорт адресы буенча аерым юридик зат - «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районы Чуаш Чабаксары башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесен төзергә.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуаш Чабаксары башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесен төзергә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксары «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе мөдире вазыйфасын «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуаш Чабаксары башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе директоры статусына күчерергә һәм кушымта нигезендә штат расписаниесн расларга.

4. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксары «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе мөдиренә:

4.1. Мәгариф оешмасын үзгәртеп кору турында карар кабул итү турында хезмәткәрләргә имза куйдырып язмача хәбәр итәргә.

4.2. Милекне инвентаризацияләү, тапшыру акты һәм финанс булмаган активларны тапшыруны чагылдырган башка документлар төзү чараларын күрергә.

5. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуваш Чебоксары төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе директорына:

5.1. Мәгариф оешмасын үзгәртеп кору турында карар кабул итү турында хезмәткәрләргә имза куйдырып язмача хәбәр итәргә.

5.2. Милекне инвентаризацияләү, тапшыру акты һәм финанс булмаган активларны тапшыруны чагылдырган башка документлар төзү чараларын күрергә.

6. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуаш Чабаксары башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе директорына:

6.1. Юридик затны үзгәртеп кору формасын (ике юридик затны бергә тоташтыру) күрсәтеп, кредиторларга үзгәртеп кору турында хәбәр җибәрергә.

6.2. «Дәүләт теркәве хәбәрләрендә» үзгәртеп кору турында хәбәрне бастырырга. Шул ук вакытта үзгәртеп кору турында хәбәрнамәдә үзгәртеп коруда

катнашучы һәр юридик зат турында белешмәләр, үзгәртеп кору формасы, кредиторларның үз таләпләрен белдерү тәртибенең һәм шартларының тасвирламасы, законда каралган башка белешмәләр күрсәтелә. Үзгәртеп кору турында икенче хәбәрнамә юридик затларны дәүләт теркәве турында белешмәләр бастырыла торган массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге массакүләм мәгълүмат чараларында юридик затны үзгәртеп кору турында беренче хәбәр урнаштырылган көннән соң бер ай узгач кына урнаштырылырга мөмкин.

6.3. Мәгариф оешмасы уставына һәм башка оештыру документларына тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә, аларны гамәлгә куючыга раслау өчен законнарда билгеләнгән срокларда тапшырырга.

6.4. Күчемсез милеккә (биналарга, корылмаларга) оператив идарә итү хокукларын һәм күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органнарда җир кишәрлекләреннән даими (сроксыз) файдалану хокукларына дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

7. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуваш Чебоксары төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесен Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына эшчәнлеген туктату турында язма кертелгәннән соң үзгәртеп корылган дип санауны билгеләргә.

8. Әлеге карар имза салынган көннән законлы көченә керә һәм Интеренет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http:/novosheshminsk.tatarstan.ru халыкка игълан ителергә тиеш.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «28» августыннан
221 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чуаш Чабаксары башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең штат расписаниесе

Директор – 1 ст.
Укытучы - 2 ст.
Тәрбияче - 1,5 ст.
Кече тәрбияче - 1 ст.
Китапханәче - 0,5 ст.
Махсус киемнәрне ремонтлау һәм юу буенча машининист - 0,25.
Хезмәт бүлмәләрен җыючы - 1 ст.
Хуҗалык эшчәнлеге мөдире - 0,5 ст.
Аш пешерүче - 1,5 ст.
Эшче - 0,5 ст.
Котельный операторы – 3 ст.
Каравылчы (вахтер) - 0,8 ст.